ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
“ ТАТАР САРСАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

"24 " сентябрь 2018 г. № 51/1

Чистай муниципаль районы
Татар Сарсазы авыл җирлеге
территориясендә гражданнарга
үзара салым кертү һәм аның акчасын
файдалану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Жирле референдум турында” 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Чистай муниципаль районы “Татар Сарсазы авыл җирлеге” Уставының 11 статьясы нигезендә, Татар Сарсазы авыл җирлеге Советының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 50/1 номерлы карары, Татар Сарсазы авыл җирлеге Башкарма комитетының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 14 номерлы карары белән, Татар Сарсазы муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 1нче төркем инвалидлардан тыш, 2019 елда 300 сум күләмендә үзара салым салуны кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә ризамы:

- Татар Сарсазы а вылында эчке суүткәргеч челтәренә ремонт ясауга;
-Татар Сарсазы һәм Уракчы авылларында авылында агачлар кисүгә;
-Татар Сарсазы һәм Уракчы авылларында ККК түгү урыны территориясен бульдозер белән төрттерүгә;

- Татар Сарсазы авылы Үзак урамында күпер төзү өчен материаллар сатып алуга, аларны урнаштыруга;

- Татар Сарсазы авылы Елга арты урамына янгын сүндерү гидранты сатып алуга һәм урнаштыруга;

- Татар Сарсазы авылы Яшьләр урамында экскаватор эшләре башкару;

- Татар Сарсазы авылына керү һәм чыгу чикләрендә ике телдә күрсәткеч стенд ясау һәм урнаштыруга. ӘЙЕ ЮК".

3. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, авыл җирлегенең халык күпләп җыела торган урыннарга, мәгълүмат стендлары һәм такталарына урнаштырырга.

Татар Сарсазы авыл җирлеге
башлыгы Н.Н.Воляков